**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Зур Сукаеш авылы №18 03 октябрь 2016 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Сукаеш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сукаеш авыл җирлеге башлыгының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 14 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 38 номерлы карарын карап,

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сукаеш авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 20 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез Сукаеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2017 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

1) Зур Сукаеш авылының җирлек юллары эчендәге чокырларны ремонтлау, гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме 62,0 мең сум күләмендә;

2 Банки Сукаеш авылының су алу скважинасын ремонтлау, гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме 24,0 мең сум тәшкил итә;

3) Түбән Сукаеш урамнарны яктырту лампаларын күләмле светодиодлыларга алыштыру

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сукаеш авыл җирлеге Башлыгы З.Җ. Закирова